СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

**17 декабрь 2020 ел** **№11**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Наласа авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, гражданнарның Наласа авыл җирлегендә җирле үзидарәгә хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан, шулай ук Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу өчен, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының «Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә яшәүче гражданнарны сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» 2009 елның 19 октябрендәге 42 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм Наласа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл
җирлеге башлыгы: И.Р.Шакирова

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
Советының 17.12.2020ел №11
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1.Гражданнарны сораштыру (алга таба - сораштыру) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге халкының турыдан-туры ихтыяр белдерү рәвешләренең берсе булып тора.

Сораштыру юлы белән гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукы гамәлгә ашырыла.

1.2. Сораштыру Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә яисә аның бер өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикерен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә исәпкә алудан гыйбарәт.

1.3. Сораштыру нәтиҗәләре киңәш итү сыйфатында.

**2. Сораштыру принциплары**

2.1. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия һәм сораштыру үткәрелә торган территория чикләрендә яшәүче Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

Гражданнарның инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда уналты яшькә җиткән, инициатив проект гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлек халкы яисә аның өлеше катнашырга хокуклы.

2.2. Сораштыруда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге халкы тигез нигезләрдә катнаша. Сораштыруда катнашучы һәр кеше бер тавышка ия һәм сораштыруда турыдан-туры катнаша.

2.3. Сораштыруда гражданнарның хокукларын җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, дингә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә бәйле рәвештә турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган чикләү рөхсәт ителми.

2.4. Гражданнарны сораштыруда катнашу ирекле һәм ихтыярый булып тора. Сораштыру барышында берәү дә үз фикерләрен һәм карашларын белдерүгә яисә алардан баш тартуга мәҗбүр ителә алмый.

2.5. Сораштыру нәтиҗәләрен әзерләү, үткәрү һәм билгеләү законлылык, ачыклык һәм хәбәрдарлык принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары халыкка сораштыруда катнашу хокукын гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә тиеш.

**3. Сораштыруга чыгарыла торган мәсьәләләр**

3.1. Сораштыруга түбәндәге мәсьәләләр чыгарыла ала:

- Наласа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагыла торган һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Уставына кергән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр;
- Төбәк һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен Наласа авыл җирлеге

җирләрен максатчан үзгәртү мәсьәләләре.

3.2. Сораштыруга чыгарыла торган сораулар Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Уставына каршы килмәскә тиеш.

Сораштыруга чыгарыла торган мәсьәләләр, аларны төрлечә аңлату мөмкинлеген булдырмас өчен, дөрес формалаштырылырга тиеш.

## 4. Сораштыруның төрләре

4.1. Сораштыру яшерен, исемле яисә ачык тавыш бирү юлы белән үткәрелә.

4.2. Яшерен тавыш бирү сораштыру уздыру пунктларында сораштыру кәгазьләре буенча бер көн эчендә үткәрелә.

4.3. Исемле тавыш бирү сораштыру үткәрү пунктларында, шулай ук сораштыруда катнашучыларның яшәү урыны буенча сораштыру үткәрү комиссиясе әгъзалары тарафыннан бер яисә берничә көн эчендә сораштыру кәгазьләре яисә сораштыру исемлекләре буенча уздырыла.

4.4. Сораштыру шулай ук гражданнар җыелышларында ачык тавыш бирү рәвешендә дә үткәрелергә мөмкин.

## 5. Сораштыруны билгеләү тәртибе

5.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге гражданнарын сораштыру түбәндәге инициатива буенча үткәрелә:

- җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Башлыгы;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирләренең төбәк һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен максатчан билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре буенча- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары.

5.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советына караган сораштыру үткәрү инициативасы күрсәтелгән орган тарафыннан сораштыру билгеләү турында тиешле карар кабул итүдә чагыла.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башлыгына караган сораштыру үткәрү инициативасы район Советына сораштыру уздыру турында үтенечнамәдә белдерелә.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органыныкы булган сораштыру үткәрү инициативасы әлеге орган тарафыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советына сораштыру уздыру турында үтенечнамәдә белдерелә.

5.3. Сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- сораштыру үткәрүне нигезләү;

- сораштыру өчен чыгарыла торган сорауның (сорауларның) тәкъдим ителә торган формулировкалары;

- сораштыру территориясе;

- сораштыру үткәрүнең фаразланган датасы һәм аның төре.

5.4. Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыру үткәрү өчен "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтын кулланылырга мөмкин.

5.5. Сораштыруны билгеләү турындагы карар сораштыру үткәрү турында үтенечнамә алынган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча һәм аны үткәрү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Сораштыру

билгеләү турында карар кабул ителгәнче Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы белән сораштыруда чыгарыла торган сорауны (сорауларны) сораштыру инициаторы белән килештерү (төгәлләштерү) булырга мөмкин.

5.6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы сораштыруга чыгарыла торган сорауны (сорауларны) формулировкалау гамәлдәге законнарга, әлеге Нигезләмәгә каршы килсә, сораштыру үткәрүдән баш тартырга хокуклы.

5.7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының гражданнарны сораштыру билгеләү турында карарында түбәндәгеләр билгеләнә:

- сораштырулар үткәрүнең датасы һәм сроклары;
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителгән) сорауның (сораулар) формулировкасы;
- сораштыру үткәрүнең методикасы;
- сораштыру кәгазенең (сораштыру исемлегенең) формасы;
-сораштыруда катнашучы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең минималь саны;
- гражданнарны сораштыру "Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтыннан файдаланып үткәрелгән очракта, сораштыруда катнашучыларны тәңгәлләштерү тәртибе.

5.8. Сораштыруны билгеләү турындагы карар аны үткәрүгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри басылып чыгарга тиеш.

## 6. Сораштыру үткәрү комиссиясе

6.1. Гражданнарны сораштыру үткәрүне сораштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) әзерли һәм уздыра.

6.2. Комиссия, инициаторлар тәкъдимнәре нигезендә сораштыру үткәрү территориясенә карап, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы тарафыннан 3 - 9 кеше исәбеннән билгеләнә.

6.3. Комиссия составына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы, Башкарма комитет вәкилләре, шулай ук сораштыру үткәрелә торган территориянең җәмәгатьчелек вәкилләре мәҗбүри кертелә.

6.4. Комиссия аны төзү турында карар кабул ителгәннән соң өченче көннән дә соңга калмыйча чакырыла. Беренче утырышта Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән рәис урынбасарын (урынбасарларын) һәм секретарен сайлый, сораштыру участокларын раслый, шулай ук, сораштыру үткәрү сораштыру пунктларында уздырылган очракта, мондый пунктларның санын һәм урынын раслый.

Комиссия рәисе Комиссия утырышларын кирәк саен чакырта. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

Комиссия гражданнарны сораштыру уздыру өчен кирәкле санда эшче төркемнәр булдырырга хокуклы.

6.5. Сораштыру участоклары, Комиссиянең урнашкан урыны һәм гражданнарны сораштыру үткәрү пунктларының урнашкан урыны сораштыру үткәрү көненә кадәр кимендә 10 көн кала басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6.6. Сораштыру үткәрү комиссиясе:

- гражданнарны сораштырганда әлеге Нигезләмәнең үтәлешен оештыра;
- сораштыру үткәрү пунктларын җиһазлый;
- сораштыру кәгазьләрен яисә сораштыру исемлекләрен әзерләүне тәэмин

итә;

- сораштырганда имзалар җыюны оештыра;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегендә яшәүчеләрнең сораштыруда катнашуын тәэмин итә;
- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә сораштыруда халыкның тавыш бирүен оештыра;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;
- гражданнарны сораштыру нәтиҗәләрен билгели;
- гражданнарны сораштыру үткәрүгә бәйле гаризаларны һәм шикаятьләрне карый;
- гамәлдәге законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы тарафыннан сораштыру нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң, Комиссиянең вәкаләтләре туктатыла.

6.8. Комиссия эшчәнлеген матди-техник, оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы аппараты тарафыннан башкарыла.

## 7. Сораштыру участоклары. Сораштыруда катнашучылар исемлекләре

7.1. Сораштыру участогы - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру алып барыла торган сораштыру үткәрү комиссиясе билгеләгән территория.

Сораштыру территориясе бердәм сораштыру участогы төзергә мөмкин.

Сораштыру участокларында тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган урыннар булырга тиеш. Участокларда тавыш бирүне сораштыру участокларына юнәлдерелгән, Комиссия әгъзаларының берсе җитәкләгән Комиссия әгъзалары тәэмин итә.

7.2. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия муниципаль берәмлек халкы кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә көн һәм ай) һәм яшәү урынының адресы күрсәтелә. Сораштыру уздыру буенча тәгаен участокта яшәүчене катнашучылар исемлегенә кертү өчен аның яшәү урыны әлеге участок территориясендә булу факты нигез булып тора. Һәр кеше сораштыруда катнашучылар исемлегенә бары тик сораштыру үткәрү буенча бер генә участокка кертелә. Сораштыруда катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә һәм исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Әлеге Нигезләмә нигезендә сораштыруда катнашу хокукы булган кешеләр исемлегенә өстәмә кертелү теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сораштыру үткәрелгән көнне дә рөхсәт ителә.

Сораштыруда катнашу хокукына ия кешеләр исемлекләренә үзгәрешләр кертү тавышларны санау башланганнан соң тыела.

Сораштыруда катнашучылар исемлеге сораштыру үткәрүгә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

## 8. Сораштыру кәгазе

8.1. Сораштыру кәгазендә сорау (сораулар) буенча үткәрелгән сорауның төгәл кабатланган тексты була һәм тавыш бирүченең "Әйе" яки "Юк" сүзләре белән ихтыяр белдерү вариантлары күрсәтелә, алар астында буш квадратлар урнаштырыла.

Сораштыруга берничә сорау чыгарылганда, алар бер сораштыру кәгазенә кертелә, эзлекле рәвештә номерлана һәм бер-берсеннән горизонталь сызыклар белән аерыла. Сораштыруга чыгарылган норматив хокукый акт проектының нинди дә булса статьяның яисә нинди дә булса пунктның альтернатив редакцияләре шулай ук эзлекле рәвештә номерлана.

Исемле тавыш бирү өчен кулланыла торган сораштыру кәгазендә тавыш бирүчеләр турында белешмәләр кертү өчен буш урын булырга тиеш.

Сораштыру кәгазендә аны тутыру тәртибе турында аңлатма бирелә. Битнең өске уң почмагында Комиссия рәисе һәм секретаре имзалары куела.

## 9. Сораштыру исемлеге

9.1. Сораштыру исемлеге исемле тавыш биргәндә кулланыла һәм графаларына сораштыруда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны турындагы белешмәләр кертелгән таблицадан гыйбарәт. Әлеге графаның уң ягында, сораштыруда чыгарыла торган (чыгарылган) сорау тексты астында, тавыш бирүченең "Әйе" яки "Юк" сүзләре белән җавап вариантлары күрсәтелә һәм тавыш бирүдә катнашучылар имзалары өчен урын кала.

Сораштыруга берничә сорау чыгарганда, алар сораштыру исемлегендә эзлекле рәвештә урнаша.

9.2.Сораштыру исемлегенең һәр битенә Комиссия рәисе һәм секретаре имза сала.

## 10. Сораштыруны үткәрү тәртибе

10.1. Сораштыру Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карарда билгеләгән көндә (яисә көннәрдә) үткәрелә.

10.2. Сораштыру үткәрү пунктларында гражданнарны сораштыру җирле вакыт буенча иртәнге сигездән кичке сәгать алтыга кадәр башкарыла.

## 11. Сораштыру үткәргәндә яшерен тавыш бирү үткәрү тәртибе

11.1. Яшерен тавыш бирү яшерен тавыш бирү урыннары өчен махсус җиһазландырылган һәм тавыш бирү вакытына мөһер сугылган тартмалар урнаштырылган сораштыру уздыру пунктларында үткәрелә.

11.2. Сораштыру кәгазе сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча тавыш бирүчегә Комиссия әгъзалары тарафыннан бирелә. Сораштыру кәгазен алганда, тавыш бирүче паспортын яисә шәхесен һәм яшәү урынын раслаган башка документны күрсәтә һәм сораштыруда катнашучылар исемлегендә үз фамилиясе турысында имза куя. Сораштыруда катнашучылар исемлегендә паспорт мәгълүматларын тутыру таләп ителми.

11.3. Әгәр тавыш бирүченең сораштыру кәгазен алганда мөстәкыйль рәвештә имза кую мөмкинлеге булмаса, ул, Комиссия әгъзаларыннан тыш, башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы.

Сораштыруда катнашучыга ярдәм итүче зат "Сораштыру кәгазен алу турында сораштыруда катнашучының имзасы" графасында үз фамилиясен күрсәтә.

11.4. Сораштыру кәгазе башка затлар булу рөхсәт ителмәгән махсус җиһазландырылган урында (кабинада яисә бүлмәләрдә) тутырыла һәм тавыш бирү тартмасына салына.

Тавыш биргәндә сораштыруда катнашучы "Әйе" яки "Юк" сүзе астындагы квадратка теләсә нинди тамга куя.

Комиссия әгъзалары сораштыру серен саклыйлар.

Сораштыру кәгазен тутырганда хата ясадым дип санаган кеше, бозылганы

урынына яңа сораштыру кәгазе бирүне үтенеп, сораштыру кәгазен биргән Комиссия әгъзасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Комиссия әгъзасы тавыш бирүчегә яңа сораштыру кәгазе бирә, шул ук вакытта сораштыруда катнашучылар исемлегендә әлеге катнашучының фамилиясе турысында тиешле тамга ясый. Бозылган сораштыру кәгазе юкка чыгарыла, бу хакта Комиссия әгъзалары тиешле акт төзи.

Тутырылган сораштыру кәгазьләре тавыш бирүчеләр тарафыннан Комиссия әгъзалары күз уңында булырга тиешле тартмага төшерелә.

Тартмалар саны Комиссия тарафыннан билгеләнә. Тавыш бирү өчен күчерелмә тартмалар кулланып тавыш бирүне уздыру мәсьәләсен Комиссия мөстәкыйль хәл итә.

11.5. Комиссия әгъзасы сораштыру серен боза яки сораштыруда катнашучыларның ихтыяр белдерүенә йогынты ясарга тырыша икән, ул шунда ук аның эшендә катнашудан читләштерелә. Читләштерү турында карар әлеге участокта Комиссиянең эшчәнлеген җитәкләүче әгъза тарафыннан тиешле беркетмә төзеп һәм участокта сораштыру уздыручы Комиссиянең барлык әгъзаларының имзалары куелып кабул ителә.

### 12. Сораштыру үткәргәндә исемле тавыш бирү уздыру тәртибе

12.1. Исемле тавыш бирү сораштыру уздыру пунктларында да, гражданнарның яшәү урыны буенча да үткәрелергә мөмкин.

12.2. Исемле тавыш бирү сораштыру кәгазьләре буенча да, шулай ук сораштыру исемлекләре буенча да үткәрелергә мөмкин.

12.3. Сораштыру исемлекләре буенча тавыш биргәндә, катнашучы паспорт яисә шәхесне һәм яшәү урынын таныклый торган башка документ күрсәтә, исемлектә үз фамилиясе турысында ихтыярына туры килә торган графада теләсә нинди тамга куя һәм имза сала.

12.4. Сораштыру кәгазьләре буенча исемле тавыш биргәндә, тавыш бирүче сораштыру кәгазенә үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, адресын язып куя, "Әйе" яки "Юк" сүзләре астындагы квадратта үз ихтыяры нигезендә теләсә нинди тамга куя һәм шунда ук кул куя.

Тавыш бирүченең үтенече буенча сораштыруда катнашучы турында мәгълүматны сораштыру кәгазенә Комиссия әгъзасы кертергә мөмкин, ләкин тавыш бирүче тиешле квадратка тамгасын үзе куя һәм имза сала.

12.5. Сораштыру үткәрү срогы дәвамында көн азагында, тутырылган сораштыру кәгазьләре сораштыру үткәрүче затлар тарафыннан Комиссиягә тапшырыла.

12.6. Сораштыру кәгазе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре Комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру исемлегенә күчерелә, ул сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү өчен төп документ булып тора.

### 13. Сораштыру үткәргәндә ачык тавыш бирү уздыру тәртибе

13.1. Комиссия, сораштыруда катнашучы халык саны 1000 кешедән артмаса, сораштыруга чыгарылган (чыгарыла торган) сорау (мәсьәләләр) буенча тавыш бирүне уздыру өчен сораштыруда катнашучылар җыелышын уздырырга хокуклы. Җыелышта катнашучыларны теркәү сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча уздырыла. Җыелышны ким дигәндә өч кеше булган Комиссия вәкилләре ача һәм алып бара. Җыелышта кызыксынучы якларның сораштыруга чыгарылган (чыгарыла торган) мәсьәлә буенча чыгышлары, аларның гражданнарның сорауларына җаваплары рөхсәт ителә, әмма фикер алышу үткәрелми.

13.2. Җыелышта һәр мәсьәлә буенча аерым "Әйе" һәм аерым "Юк" тавыш бирү үткәрелә. Тавыш бирүдә исемлеккә кертелгән һәм җыелышта теркәлгән

сораштыруда катнашучылар гына катнаша. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул җыелышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

13.3.Җыелыш сораштыруда катнашучылар исемлегенә кертелгән халыкның 25 проценттан артыгы катнашканда тулы хокуклы була.

## 14. Сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү

14.1. Сораштыру үткәрелгәннән соң Комиссия сораштыру участоклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен саный һәм сораштыру йомгаклары турында карарны сораштыру йомгаклары турында беркетмә белән рәсмиләштерә, анда түбәндәге белешмәләр бирелә:

- беркетмәне төзү датасы;
- сораштыру уздыру сроклары: башлану һәм тәмамлану даталары;
- сораштыру үткәрү участогы адресы;
-сораштыру территориясе (әгәр сораштыру шәһәр территориясе өлешендә үткәрелсә, һичшиксез микрорайоннарның, урамнарның, йорт номерларының исемнәре күрсәтелә);
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган (тәкъдим ителгән) сорауның (сораулар) формулировкасы;
- сораштыруда катнашу исемлегенә кертелгән гражданнарның гомуми саны;
- сораштыруда катнашкан гражданнар саны;
- сораштыруны узган яисә узмаган дип тану;
- сораштыру гамәлдә яисә гамәлдә түгел дип тану;
- сораштыру исемлегендә дөрес түгел дип танылган язмалар саны яисә дөрес түгел дип танылган сораштыру кәгазьләре саны;
- сораштыруда чыгарылган сорауга "Әйе" дип бирелгән тавышлар саны;
- сораштыруда чыгарылган сорауга "Юк" дип бирелгән тавышлар саны;
- Сораштыру нәтиҗәләре (сорау, аңа җавап биргәндә тавыш бирүдә катнашкан сораштыруда катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, хупланган дип санала).

14.2. Әгәр сораштыру берничә мәсьәлә буенча үткәрелгән булса, тавышларны санау һәм беркетмә төзү һәр мәсьәлә буенча аерым башкарыла.

14.3. Сораштыру кәгазендәге язмалар түбәндәге очракларда дөрес түгел дип санала:

- сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес билгеләү мөмкин булмаганда;
- язмада тавыш бирүче турында мәгълүмат яисә аның имзасы булмаганда;
-кабатлана торган язмалар булганда.

Сораштыру кәгазьләре дөрес түгел дип таныла:

- билгеләнгән үрнәктәгечә булмаганда,
- Комиссия әгъзаларының билгеләре булмаганда,
- алар буенча сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес билгеләү мөмкин булмаганда.

14.4. Әгәр сораштыруда катнашкан кешеләр саны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы карары белән муниципаль берәмлектә яшәүчеләрнең билгеләнгән сораштыруда катнашачак минималь санынннан кимрәк булса, Комиссия сораштыруны узмаган дип таный.

14.5. Түбәндәге очракларда Комиссия сораштыру нәтиҗәләрен дөрес түгел дип таный:

- сораштыру үткәргәндә җибәрелгән хокук бозулар гражданнарның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәгәндә;
- сораштыру исемлегендә дөрес дип танылган язмалар саны сораштыруда

катнашкан гражданнар санының 80 процентттан кимрәген тәшкил иткәндә;

- дөрес дип танылган сораштыру кәгазьләре саны сораштыруда катнашкан гражданнар санының 80 процентттан кимрәген тәшкил иткәндә.

14.6. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмә 2 нөсхәдә төзелә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәгә имза салган вакытта Комиссиянең кайбер әгъзалары булмаган очракта, беркетмәдә аларның булмау сәбәпләрен күрсәтеп, язма ясала.

Комиссия әгъзасы беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән ризалашмаса, үз фикерен беркетмәгә кушымта итеп бирелә торган язма рәвешендә бәян итәргә хокуклы, бу хакта беркетмәдә тиешле язма ясала. Беркетмә, әгәр ул Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы карарында билгеләнгән сораштыру комиссиясе әгъзаларының күпчелеге тарафыннан имзаланган булса, гамәлдә була.

Беркетмәгә имза салу көне булып Комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләрен билгеләгән көн тора.

14.7. Беркетмәнең беренче нөсхәсе Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советына сораштыру кәгазьләре яисә сораштыру исемлекләре белән бергә җибәрелә, беркетмәнең икенче нөсхәсе сораштыру үткәрү инициаторына җибәрелә.

Беркетмәнең беренче нөсхәсенә Комиссиягә кергән язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә теркәлә.

Беренче нөсхәнең күчермәләре массакүләм мәгълүмат чараларына, җирле иҗтимагый берләшмәләргә һәм территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына тапшырылырга мөмкин.

14.8. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге комиссиясе һәм Советы тутырылган сораштыру кәгазьләренең һәм сораштыру исемлекләренең һәм сораштыру уздыру документларының кагылгысызлыгын һәм сакланышын тәэмин итәләр.

## 15. Сораштыру нәтиҗәләре

15.1.Сораштыру нәтиҗәләре аларны билгеләгән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

15.2.Сораштыру барышында ачыкланган халык фикере тәкъдим итү характерында. Сораштыру нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә һичшиксез каралырга һәм исәпкә алынырга тиеш.

15.3.Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары сораштыру нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул иткән очракта, күрсәтелгән органнар тиешле карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә әлеге мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән мондый карар кабул итү сәбәпләрен халыкка җиткерергә тиеш.

## 16. Сораштыру материалларын саклау

16.1.Сораштыру материаллары Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы депутатларының вәкаләтләре вакыты ахырына кадәр саклана, аннары муниципаль архивка саклауга җибәрелә.

16.2.Күрсәтелгән материалларны саклау срогы Татарстан Республикасы Арча

муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, әмма 1 елдан да ким була алмый.

## 17. Сораштыру үткәрүне финанслар белән тәэмин итү

17.1. Гражданнарны сораштыру әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау түбәндәге акчалар хисабына гамәлгә ашырыла:

- җирле үзидарә органнары яки муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру уздырганда -җирле бюджет;
- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән сораштыру уздырганда - Татарстан Республикасы бюджеты.

## 18. Сораштыруда катнашуга гражданнарның хокукларын бозган өчен җаваплылык

18.1. Көч куллану, сатып алу, янау, документлар ясау юлы белән яисә Россия Федерациясе гражданы тарафыннан сораштыруда катнашу хокукын ирекле гамәлгә ашыруга комачаулый торган башка ысул белән яисә комиссия эшенә яки комиссия әгъзалары эшенә каршылык тудырган затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тоталар.